КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 25 февраль г.Казань № 130

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы, 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче, 2013 ел, 29 июнь, 458 нче, 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы, 2014 ел, 15 февраль, 91 нче, 2014 ел, 29 июль, 553 нче, 2014 ел, 2 август, 565 нче, 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче, 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче, 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы, 2015 ел, 22 июль, 536 нчы, 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче, 2016 ел, 26 май, 356 нчы, 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы, 2017 ел, 16 март, 144 нче, 2017 ел, 20 июнь, 400 нче, 2017 ел, 5 сентябрь, 636 нчы, 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы, 2018 ел, 14 июнь, 482 нче, 2018 ел, 15 июнь, 486 нчы, 2018 ел, 16 ноябрь, 998 нче, 2019 ел, 17 июль, 594 нче, 2019 ел, 28 август, 715 нче, 2019 ел, 22 октябрь, 952 нче, 2019 ел, 6 декабрь, 1110 нчы, 2021 ел, 2 апрель, 212 нче, 2021 ел, 20 июль, 605 нче, 2021 ел, 26 июль, 645 нче, 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы, 2022 ел, 10 июнь, 543 нче, 2022 ел, 20 июнь, 587 нче, 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче, 2023 ел, 3 июль, 779 нчы, 2023 ел, 16 октябрь, 1312 нче, 2023 ел, 15 декабрь, 1621 нче, 2024 ел, 28 март, 192 нче, 2024 ел, 6 июнь, 409 нчы, 2024 ел, 12 сентябрь, 765 нче, 2025 ел, 19 апрель, 251 нче, 2025 ел, 27 сентябрь, 773 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.2 пункт  таблицасыннан соң беренче абзацта «акылга зәгыйфь балалар өчен интернат йортлары» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү балалар йортлары» сүзләренә алмаштырырга;

6.3 пунктның 6.3.7 пунктчасындагы беренче абзацта «психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән  балалар интернат йортлары,» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү балалар йортлары» сүзләренә алмаштырырга;

25 нче таблицада:

25 таблицаның «Акылга зәгыйфь балалар өчен балалар интернат  йортлары, физик җитешсезлекләре булган балалар өчен балалар интернат йортлары» юлының 1 нче графасында «Акылга зәгыйфь балалар өчен балалар интернат  йортлары» сүзләрен «Социаль хезмәт күрсәтү балалар йортлары» сүзләренә алмаштырырга;

«Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортлары» юлының 1 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтү йортлары»;

«Социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләре, гаиләгә һәм балаларга ярдәм итү үзәкләре» юлының 1 нче графасында «, гаиләгә һәм балаларга ярдәм итү үзәкләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

9.3 пунктның өченче абзацында «психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән  балалар интернат йортлары» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү балалар йортлары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы таблицасының баш исемендә:

4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтү йорты»;

6 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтү балалар йорты»;

12 нче графада «, гаиләгә һәм балаларга ярдәм итү үзәге» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымтада:

2 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Социаль хезмәт күрсәтү йорты»;

3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Социаль хезмәт күрсәтү балалар йорты»;

6 бүлек үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карарның гамәле 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин